СОВЕТ УРМАНЧЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ленина, д.5, п.Зверосовхоза,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422186

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УРМАНЧЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Ленин ур., 5 нче йорт, Жәнлек совхозы поселогы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422186

тел.(факс): (85563) 2-12-50; e-mail: Urman.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**Решение** **Карар**

19 февраль 2020 ел № 3-53

Урманчы авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 11 апрелендәге 1-34 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы_ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен Төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешенең 16 пунктын үз көчен югалткан дип тану хакында» 2019 елның 18 июлендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Урманчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Урманчы авыл җирлеге Советының 2018 елның 11 апрелендәге 1-34 номерлы карары (2018 елның 17 сентябрендәге 2-38 номерлы редакциясендә) белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен Төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 29 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«29. Гомуми файдаланудагы барлык парковкаларда, шул исәптән социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары (торак, җәмәгать һәм житештерү бианалары, төзелеш һәм корылмалар, шул исәптән физкультура-спорт оешмалары, мәдәният оешмалары һәм башка оешмалар урнашкан урыннарны да кертеп), ял урыннарында, I, II төркем инвалидлары идарә иткән транспорт чараларын һәм мондый инвалидларны һәм (яки) инвалид балаларны

йөртүче транспорт чараларын түләүсез кую өчен кимендә 10 процент урын (әмма бер урыннан да ким түгел) бүлеп бирелә. III төркем инвалидлары арасыннан булган гражданнарга әлеге өлеш нормалары Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә тарала. Күрсәтелгән транспорт чараларында «Инвалид» танып-белү билгесе куелырга һәм бу транспорт чаралары турында мәгълүмат инвалидларның Федераль реестрына кертелгән булырга тиеш.»

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында, Мамадыш муниципаль районы http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, "Интернет" мәгълүмати-коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Урманчы_ авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Урманчы авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /А.Я.Ильин/